**СОВЕТ ЧЕРНЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, д.Чернышевка, ул. Клубная, 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕРНЫШЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чернышевка авылы, Клуб урамы, 1

Тел./факс: +7(84365) 73-5-05, e-mail: Chern.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10 декабрь 2024 ел №109

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышевка авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге Уставы, Биектау муниципаль районының Чернышевка авыл җирлеге Советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышево авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан, күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чернышево авыл җирлеге башкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

Совет Рәисе,
Чернышевка авыл җирлеге башлыгы О.А. Маланин